**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2015 ел, 14 октябрь

№ 767

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 15 август, 388 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 20 сентябрь, 492 нче; 2007 ел, 29 декабрь, 788 нче; 2008 ел, 17 ноябрь, 818 нче; 2009 ел, 22 июнь, 418 нче; 2010 ел, 1 апрель, 217 нче; 2010 ел, 6 декабрь, 1003 нче; 2010 ел, 10 декабрь, 1041 нче; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 13 декабрь, 1013 нче; 2012 ел, 2 июль, 576 нчы; 2012 ел, 17 сентябрь, 774 нче; 2013 ел, 22 май, 341 нче; 2013 ел, 22 август, 592 нче; 2013 ел, 26 октябрь, 799 нчы; 2013 ел, 19 ноябрь, 896 нчы; 2014 ел, 18 апрель, 253 нче; 2014 ел, 31 май, 372 нче; 2014 ел, 16 сентябрь, 665 нче; 2014 ел, 24 ноябрь, 902 нче; 2014 ел, 12 декабрь, 983 нче; 2015 ел, 11 июнь, 433 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 бүлекнең 3.3.11 нче пунктындагы уникенче абзацка «аның турында нигезләмәләр раслый» сүзләреннән соң «яки Министрлык каршындагы иҗтимагый советка социаль хезмәт күрсәтү оешмалары тарафыннан хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләүне үткәрү вазыйфаларын йөкли» сүзләрен өстәргә;

5 бүлекнең 5.3 нче пунктындагы өченче абзацка «ведомство буйсынуындагы учреждениеләре җитәкчеләре» сүзләреннән соң «, Министрлык каршындагы иҗтимагый совет рәисе» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин

F:\KARAR\2015\767.docx